**СОВЕТ ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422612 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПӘРӘҮ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422612 Пәрәү авылы,
Совет урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

---

**2024лның 30 ноябре** **37 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Пәрәү авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлегендәге Пәрәү торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Пәрәү авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 500 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау буенча эшләр өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Пәрәү авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.Ф.Тимергалиев

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Пәрәү
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Ф.Тимергалиев